СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.05.2024 г. Агрыз № 37-8

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында коррупциячел хокук бозулар кылган өчен муниципаль хезмәткәрләрнең җаваплылыгы турында» 2015 елның 28 гыйнварындагы 39-10 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2019 елның 432-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында коррупциячел хокук бозулар кылган өчен муниципаль хезмәткәрләрнең җаваплылыгы турында» 2015 елның 28 гыйнварындагы 39-10 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. I бүлекнең 1.3 пункты. Коррупциячел хокук бозулар кылган өчен муниципаль хезмәткәрләргә карата дисциплинар җаваплылык һәм дисциплинар түләтүләр чараларын куллануны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елның 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә».

1.2. II бүлектә. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 статьяларында каралган дисциплинар җаваплылык чараларын һәм дисциплинар җәза чараларын муниципаль хезмәткәрләргә карата куллану үзенчәлекләре «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 27.1 статьясында каралган тәртиптә:

- 2.4 пунктының икенче һәм өченче абзацында «,Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

- 2.5 пунктның икенче абзацын «яисә 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» гы Федераль законның 13.4 статьясына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан тулыландырырга».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе урынбасары,
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев